КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 29 октябрь г.Казань № 796

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы; 2006 ел, 19 июнь, 312 нче; 2010 ел, 31 май, 419 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы; 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы; 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы; 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы; 2013 ел, 19 март, 185 нче; 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы, 2016 ел, 19 март, 150 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктның җитмешенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«транспорт иминлеге турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән компетенция нигезендә транспорт инфраструктурасы объектларында транспорт иминлеген тәэмин итүдә катнаша һәм транспорт иминлеген тәэмин итү буенча мәгълүматны җыюны, гомумиләштерүне һәм исәпкә алуны гамәлгә ашыра;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков